**СОВЕТ РОЖДЕСТВЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422631с.Дятлово,
ул. Юности, д.1
тел: 4-74-98

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ РОЖДЕСТВЕНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422631 Дятлово авылы,
Яшьлек урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-74-98

---

**2026елның 6 апреле** **46 номер**

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советының аерым карарларын үз көчен югалткан дип тану турында**

Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм аларны үз көчен югалткан дип тану турында»гы 1009 нчы номерлы Указының 4 нче пунктына ярашлы, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип таныйрга:

1)Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советының 2023 елның 17 гыйнварындагы «Рождествено авыл җирлеге Советының 2016 елның 15 апрелендәге “Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнарның керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тәкъдим итүе, шулай ук Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлегендәге муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тәкъдим итүе турындагы Нигезләмәне раслау турында”гы 34 нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 145 нче номерлы карарын;

2)Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советының 2022 елның 30 мартындагы «“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфаларын һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү Тәртибен раслау турында”гы Рождествено авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 сентябрендәге 76 нчы номерлы карарына үзгәрешләр һәм тулыландырулар кертү турында»гы 108 нче номерлы карарын.

3) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советының 2017 елның 7 сентябрендәге «“Татарстан Республикасы

Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге муниципаль вазыйфаларын һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматны “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтта урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү Тәртибен раслау турында»гы 76 нчы номерлы карарын;

4)Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советының 2013 елның 28 августындагы “Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Рождествено авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатыннарының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тәкъдим итү турында” Рождествено авыл җирлеге Советының 2010 елның 11 мартындагы 7/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»гы 13 нче номерлы карарын;

5) Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советының 2013 елның 11 мартындагы «Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатыннарының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тәкъдим итү турында»гы 7/2 номерлы карарын;

6)Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге Советының 2012 елның 13 декабрендәге «Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның, Лаеш муниципаль районы Рождествено авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең һәм аларның гаилә әгъзаларының керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматын Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру һәм әлеге мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен тәкъдим итү Тәртибен раслау турында»гы 27 нче номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылган (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам

**Башлык-Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы Рождествено**
**авыл җирлеге Советы рәисе** **С.М. Гуцу**